**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**

**КАРАРЫ**

**2022 елның 14 ноябре** **№ 6**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 25 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Үрәсбаш авылы, Пионер урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 25 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Үрәсбаш авылы, Пионер урамы, 21 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Үрәсбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру , килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары);

- Үрәсбаш авылы  территориясен төзекләндерү;?

«РИЗА» «КАРШЫ»».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы В.Г. Сафаров